ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

6 декабрь, 2024 ел № 39/7

Товарлар, эшләр, хезмәтләр күрсәтүне сатып алуны формалаштыру, үтәү һәм гамәлгә ашыруны контрольдә тоту тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 29 мандагы 124-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2014 елның 9 декабрендәге 35/8 номерлы Карары белән расланган товарлар, эшләр, хезмәтләр күрсәтүне сатып алуны формалаштыру, үтәү һәм гамәлгә ашыруны контрольдә тоту тәртибе турында Нигезләмәгә (Шәһәр Советының 2015 елның 15 апрелендәге 39/9, 2016 елның 24 февралендәге 6/7, 2018 елның 8 ноябрендәге 27/8, 2019 елның 24 гыйнварындагы 29/8, 2019 елның 7 октябрендәге 33/8, 2021 елның 9 декабрендәге 10/5 номерлы Карарлары редакциясендә) 3 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«2) заказчы - муниципаль заказчы яки Федераль законның 15 статьясындагы 1, 2.1, 4 өлешләре нигезендә сатып алуларны гамәлгә ашыручы бюджет яисә автоном учреждение, муниципаль унитар предприятие яисә башка юридик зат;».

2. Әлеге Карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш.Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев